СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2024 г. Заинск №156

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль законнарга, 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставының нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2005 елның 5 декабрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кушымтага ярашлы үзгәрешләр кертергә.
2. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кертелгән үзгәрешләрне җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвеннән соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыккач үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башлыгы урынбасары Е. В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына кушымта
«06.03.» 2024 елдан № 156

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына**
**үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1. 7 нче статьяда :

а) 1 нче өлешнең 29 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) 1 нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге 39 нчы пункт белән тулыландырырга:

«39) тирә-яктагы мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыру.».

2. 29 нчы статьяда:

а) 5.2 өлешнең 2 пунктында:

- «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләре белән алыштырырга;
- «б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенә» сүзләре белән алыштырырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге 6.1 өлеш белән тулыландырыгыз:

«6.1. Әгәр депутат Шәһәр Советының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез булмаса, Шәһәр Советы депутатының вәкаләтләре Шәһәр Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) 7 нче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

г) 8 нче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

д) 9 нчы өлеш үз көчен югалткан дип танырга;

е) түбәндәге эчтәлектәге 12 өлеш белән тулыландырырга:

«12. Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, Россия Федерациясендә үзидарә һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатында, әгәр мондый чикләүләрне үтәмәү очрагында, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан тыюлар һәм таләпләр, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү танылa.».

3. 32 статьясының 13 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

4. 39 нчы статьясының 2 нче өлешендәге 2.2 нче пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

5. 41 нче статьясының 1 нче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

6. 42 статьясында:

а) 3 нче өлешнең 2 нче пунктында:

- «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенә» сүзләре белән алыштырырга;
- «б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенә» сүзләре белән алыштырырга»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 7 өлеш белән тулыландырырга:

«7. Шәһәр Башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы чикләүләрне, таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында"гы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган аңа бәйле булмаган шартлар тәртибе нәтиҗәсендә танылa.».

7. 45 нче статьясының 4 нче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

8. 49 нчы статьясында:

а) 3 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- әйләнә - тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыра.»;

б) 5 нче пунктның 8 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;».

9. 49 нчы статьясын түбәндәге эчтәлектәге 7 нче өлеш белән тулыландырырга:

«7. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм таләпләрне үтәмәгән өчен шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыктан азат ителә һәм таләпләр, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар тикшерүе тарафыннан танылa.».

10. 53 нче статьясында:

а) 2 нче өлешнең 2 нче пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

б) 2.1 нче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга»;

11. 57 статьясы үз көчен югалткан дип таныргa.

12. 78 статьясының 3 өлешендә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен алырга.

13. 88 статьясының 1 өлеше 9 пунктында «һәм мәдәният» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халыклары» сүзләре белән тулыландырырга (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)»;